Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

07 ноябрь 2019 ел N 1

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Ямаши авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 20 ноябрендә, 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында Дачная, Заречная, Кияткин, Болын, Нагорный, Яр Буе, Октябрьская урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 21 ноябрендә, 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында Подстанция, Кыр, Почта, Совет, Университет, Шоссейная, 8 Март урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслаграга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 200 сум (биш йөз) күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерүгә?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Ямаши авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Ямаши авылы, Совет урамы, 4 нче йорт.
5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Ямаши авылы, Совет урамы, 4 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Ямаши
авыл җирлеге башлыгы — А.А. Андревкина